**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге составына керүче Сатлыган авыл торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

№1

2021 елның 29 ноябре

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге X номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә", Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгының « Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллысы, Мәмле Казаклар Чаллысы, Сатлыган авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында»гы 2021 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Сатлыган авылы гражданнар Җыенының 2021 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы йомгаклау беркетмәсен игътибарга алып, халык җыены карар итте:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Сатлыган авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге формада белем алучы студентлардан, тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз япа-ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәм аларның гомуми саны җирлектә яшәүчеләрнең 30% тан артмаган очракта, 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен кулланырга:

1) кышкы юлларны кардан чистарту;
2) Сатлыган авылы урамнарына вак таш җәю;
3) урам утларының светодиод лампаларына хезмәт күрсәтү;
4) вак таш тигезләү өчен трактор хезмәтләренә түләү;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов